КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 7 март г.Казань № 202

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты мәсьәләләре» 2017 ел, 15 декабрь, 996 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты хакындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты мәсьәләләре» 2017 ел, 15 декабрь, 996 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 26 февраль, 110 нчы; 2018 ел, 7 май, 327 нче; 2018 ел, 30 июль, 614 нче; 2018 ел, 29 декабрь, 1288 нче; 2019 ел, 23 апрель, 329 нчы; 2019 ел, 18 декабрь, 1165 нче; 2020 ел, 11 февраль, 87 нче; 2020 ел, 15 май, 392 нче; 2020 ел, 8 август, 666 нчы; 2021 ел, 17 июнь, 467 нче; 2021 ел, 11 август, 700 нче; 2021 ел, 6 сентябрь, 817 нче; 2021 ел, 27 ноябрь, 1140 нчы; 2021 ел, 9 декабрь, 1209 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

түбәндәге эчтәлекле 4.1.15 пункт өстәргә:

«4.3.15. Дәүләт комитетының вазыйфаи затлары Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 20.61 статьясында каралган административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә хокуклы.».

2. Түбәндәгеләр дип билгеләргә:

бу карарның 1 пунктындагы өченче абзацының гамәле 2022 елның 31 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла;

бу карарның 1 пунктындагы өченче абзацы 2021 елның 31 декабренә (31 декабрьне кертеп) кадәр гамәлдә була.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин